**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 19 августындагы 2908 номерлы карары**

**Яшь гаиләләрнең түли алу мөмкинлеген исәпләү өчен**
**2026 елның өченче кварталына Казан шәһәрендә гомуми торак**
**мәйданының бер квадрат метры бәясе нормативын билгеләү турында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 17 декабрендәге 1050 номерлы «“Россия Федерациясе гражданнарын һәркем алырлык уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү” Россия Федерациясе дәүләт программасының аерым чараларын гамәлгә ашыру турында»гы карарын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 3 октябрендәге 888 номерлы «“Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре белән тәэмин итү” дәүләт программасын раслау турында»гы карарын гамәлгә ашыру максатыннан һәм Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2026 елның 19 июнендәге 388/пр номерлы «2026 елның икенче яртыеллыгына Россия Федерациясе буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метры бәясе нормативы һәм 2026 елның III кварталына Россия Федерациясе субъектлары буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар бәясе турында»гы әмерен исәпкә алып **карар бирәм**:

1. Яшь гаиләләрнең түли алу мөмкинлеген исәпләү өчен 2026 елның өченче кварталына Казан шәһәрендә торакның гомуми мәйданының бер квадрат метры бәясе нормативын 170 477 сум күләмендә билгеләргә.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.Ә.Гыйниятуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**